МӨКЛИСЕ ДӘ ЧҮТЛЫЙСЫ

Республика төзүчеләре рекорд куйган

> 2

КЕСӘНЕ ТИШМИ

Студентларга яңа стипендия булдырыла

> 3

ТЫЕЛГАН ҖИМЕШ

Куркыныч күренешләрне романтикага төрү гадәткә керә башлады

> 4

75 ЯШЬЛЕК БЛОГЕР

Мөхәрәм Мөхәммәтҗанов кешеләргә файда китерергә тели

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 19 (28792) | Чәршәмбе | 9 февраль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

ТЕЛЕФОННАН БЕР ДӘШҮЕҢ ҖИТӘ...

РОССИЯДӘ МОШЕННИК КОРБАННАРЫ САНЫ АРТА

Яшәргә өйрәнәбез

Казанда яшәүче 44 яшьлек хатын, булмаган кредитны каплыйм дип, ярты миллион сум акчасыннан колак каккан. Билгесез номердан шалтыратып, үзен банкның саклык хезмәткәре дип таныштырган билгесез зат аның исеменә кредит рәсмиләштерергә маташуларын хәбәр иткән. Аның сүзенә ышанган ханым, операцияне туктату өчен, онлайн рәвештә генә 436 мең сумлык кредит рәсмиләштергән. Теләгәненә ирешкәч, теге билгесез заттан җилләр искән.

Алданганын аңлап, теге номерга күпме генә шалтыратса да, трубканы алучы булмаган. Әле бер атна элек кенә хокук сакчылары башкаладагы тагын бер ханымның шушы ук юл белән төп башына утырганлыгы турында хәбәр иткән иде.

Кисәтә торалар, алдана торабыз, кыскасы. Мошенниклар да үз тормышы белән яшәвен дәвам итә. Аларга каршы көрәш максатында кабул ителгән законнар да вазгыятьне үзгәртә алмый. Хәтерләсәгез, узган елның ноябрендә шундый кануннарның берсе үз көченә керде. Аның нигезендә кәрәзле элемтә операторларына шикле тоелган, кырыгалдарлык очракларында кулланылган номерларны автомат рәвештә «туңдыру» хокукы бирелде. Проект авторлары бу закон кабул ителү белән халыкны телефон аша төп башына утырту очраклары икеләтә кимеячәк дип өметләнгән иде. Әмма алдану очраклары, киресенчә, күбәйгән генә. Рәсми саннарга ышансаң, соңгы ике айда гына да илдә телефон аша алданучылар саны 1,5 тапкыр арткан.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Аптыраган үрдәк арты белән суга чума, дигәндәй, шушы шартларда Үзәк банк гамәлдәге законга тагын бер яңа төзәтмә әзерләгән. Белгечләр мошенниклар тарафыннан алданган банк клиентларына югалткан акчаларын тулысынча кире кайтарырга тәкъдим итә. Әмма сөенергә иртәрәк. Бу мөмкинлек банк гаебе белән алданган кешеләргә генә биреләчәк. Югалткан акчаны интернет аша эшләнә торган «һөҗүм»нәргә каршы торучанлыгы түбән булган банк клиентлары гына кайтара алачак. Банк куркынычсызлык мәсьәләсенә салкын караган, клиентлары да шуңа алданган, кыскасы. Югалткан акчаны тулысынча кайтару өчен иң элек әнә шуны дәлилләргә туры киләчәк. Монысы инде бәхет эше.

Юрист Роман Архипов та бу яңалыкка сагаеп карый.

– Бу төзәтмәләр үз көченә керә калса да, андый мөмкинлектән күпләр файдалана алыр дип уйламыйм. Интернет аша эшләнә торган «һөҗүм»нәргә каршы торучанлыгы түбән дигәндә нәрсә күздә тотыла? Ул нинди критерийлар буенча бәяләнәчәк? Әнә шушы пунктлар төгәл билгеләнмичә, банкның гаебен дәлилләү кыен булачак. Шул рәвешле югалткан акчаны тулысынча кайтару ихтималы да кими, – ди юрист.

Хәтерләсәгез, узган ел азагында Үзәк банк гамәлдәге законга шушы юнәлештә тагын бер төзәтмә әзерләгән иде. Белгечләр кырыгалдарлар аркасында исәп-хисап счетыннан акчасын югалткан кешеләргә бу сумманың кире кайтарыла торган өлешен арттырырга тәкъдим итте. Билгеле булганча, әлегә банклар андыйларга суга салган акчасының күп дигәндә 8 процентын гына кире кайтара ала. Үзәк банк тәкъдим иткән төзәтмәләр кырыгалдарлар тарафыннан алданган кешеләргә кире кайтарыла торган югалткан акчаның минималь күләмен билгеләүне күздә тота. Дөрес, әлегә аның төгәл суммасы билгеле түгел.

Ахыры 2 нче биттә >

Мошенниклар корбаны булмас өчен киңәшләр:

- банк хезмәткәрләре беркайчан да клиентларының шәхси мәгълүматларын сорап, йә булмаса, акчаңны югалта аласың, дип куркытып шалтыратмый;
- алар клиентның банк картасы номерларын, смс аша килгән парольләрне сорамый;
- банк хезмәткәре башта кредит рәсмиләштереп, аннары шуны ниндидер билгесез счетларга күчерүне сорамый;
- телефоннан шалтыраткан «банк хезмәткәре» кушуы буенча телефоныгызга ниндидер кушымталар йөкләтүдән дә сакланыгыз;
- үзегез турындагы шәхси мәгълүматны, банк картасы номерларын, смс аша килгән кодларны беркемгә дә хәбәр итмәгез;
- сезгә чынлыкта кемнең шалтыратуын банкның «кайнар элемтә»сенә шалтыратып белешегез. Аның номеры банк картасының арткы ягында күрсәтелә. Эчке эшләр органнарына да мөрәҗәгать итү комачауламас.

«Хәтер уты» бушлай яначак

Россия Президенты Владимир Путин Хөкүмәт белән «Газпром» компаниясенә «Мәңгелек ут»лар һәм истәлекле көннәр уңаеннан кабызыла торган «Хәтер уты» өчен газны бушлай бирергә кушты. Моңа җаваплы итеп Премьер-министр Михаил Мишустин, «Газпром» башлыгы Алексей Миллер билгеләнде, дип хәбәр итә Мәскәү Кремленең матбугат хезмәте. Россия Президентына 1 майга кадәр бу җәһәттән башкарылган эшләр турында җиткерелергә тиеш.

Шалтыратып дәвалыйлар

Табиблар коронавирустан, үпкә ялкынсынуы, ОРВИ яки гripптан дәваланучыларга 15 мартка кадәр телефон аша гына киңәш-табыш бирәчәк. Россия Хөкүмәте сырхауны өендә килеш кенә дәвалаучы Татарстан медикларына хезмәт хакы түләү өчен 14,9 миллион сум акча бүлеп бирә. Премьер-министр Михаил Мишустин имзалаган боерык хокукый мәгълүматлар рәсми порталына урнаштырылган.

Хөкүмәт барлык төбәкләргә бу максатка җәмгысы 600 миллион сум акча бирергә җыена. Чир йоктыручыларга телефон аша дарулар язу, киңәшләр бирү, «больничный»лар ачу өчен тагын 2,5 меңгә якын медицина хезмәткәрен эшкә җәлеп итү кирәк. Акча төбәкләр бюджетларына медиклар хезмәтенә түләү өчен максатчан трансферт рәвешендә җибәрелә.

Сүз уңаеннан, Хөкүмәт гыйнвар аенда табиблар һәм шәфкать туташларына хезмәт хакына түләү өчен республикага өстәмә 464,7 миллион сум акча биргән.

Таныклык электронлаша

1 марттан үлү турында таныклык электрон рәвештә генә бирелә башлаячак. Премьер-министр Михаил Мишустин бу җәһәттән тиешле карарга кул куйган. Документта әйтелгәнчә, Сәламәтлек саклау министрлыгы мондый таныклыкларның бердәм федераль реестрын алып барачак.

Электрон таныклык тутыру мәҗбүри итеп куелачак. Башта кешенең үлү сәбәбе, медицина оешмасы турында барлык мәгълүматлар сәламәтлек саклау өлкәсенең мәгълүмат системасына кертелә. Шуннан соң алар ЗАГСның Бердәм дәүләт реестрына, Росстат һәм башка ведомстволарга җибәреләчәк.

Медицина документының электронлаштырылуы үлгән кешенең якыннарын төрле инстанцияләргә йөрү мәшәкатеннән коткарачак. Әйтик, моңарчы үлү турында таныклыкка кешенең вафаты хакында язып кую өчен ЗАГС органына барырга кирәк иде. Кешеләр якынының үлү турында электрон документларны «Дәүләт хезмәтләре» порталыннан шәхси кабинетка кереп алачак.

Сүз уңаеннан, Татарстанда ел ахырында электрон паспортлар бирелә башлаячак. Республика пилот төбәкләр исемлегенә кертелгән, шуңа күрә без цифрлы паспортларны беренчеләрдән булып алачакбыз.

Вакыйга

Ачкычны Казанга тапшыралар

Казан – ислам дөньясының яшьләр башкаласы. Татарстан мәркәзенә быел әнә шундый дәрәҗәле исем бирелде. Әлеге вакыйганың Идел Болгарында ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулу белән бер елны туры килүе аеруча игътибарга лаек.

Казанның мондый дәрәҗәгә лаек булуы юкка түгел. «Бай мәдәни мирасы, сәләтле яшьләре, заманча инфраструктурасы, эшмәкәрлек, инновацияләр, спорт тармагында эшләүче яңалык кертүче институтлары, ислам дөньясы илләрендә яшәүче яшьләргә бирерлек зур потенциалы булганга күрә Казан ислам дөньясының яшьләр башкаласы дип танылуга лаек дип табылды», – дип сөйләде журналистлар белән очрашуда Ислам хезмәттәшлеге оешмасының яшьләр форумы Президенты Таха Айхан.

Татарстан яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов әйткәнчә, март аенда Мәскәүдә узачак тантаналы чарада Казан рәсми рәвештә ислам дөньясының яшьләр башкаласы дип игълан ителәчәк. Анда Россия тышкы эшләр министры Сергей Лавров та катнашыр дип көтелә. Бу көнне республика вәкилләренә шушы дәрәҗәле исемне символлаштырган алтын ачкыч тапшырылачак. Алтын ачкыч Татарстан Яшьләр эшләре министрлыгында яисә башкаладагы музейларның берсендә сакланыр дип көтелә. Аны Татарстан шәһәрләре буйлап сәяхәткә җибәрергә дә хыялланалар.

Тимур Сөләйманов белдерүенчә, бу вакыйга уңаеннан Казанда узачак чаралар Коръән укучылар бәйгесеннән башланып китәчәк. Ул рамазан ае башланыр алдыннан – март ахырында узачак. Бәйге ислам дөньясы илләреннән җыелган яшьләрне берләштерер дип көтелә. Моннан тыш башкалада халыкара яшьләр форумы, спорт ярышлары, фәнни саммит та узачак. «Май ахырында Казанга дөньяның 56 иленнән яшьләр эшләре министрлары да җыелачак. Әлеге съездда мәдәни багланышлар, яшьләр сәясәтен оештыру мәсьәләләре каралачак. Дөнья күләмендә яшьләр сәясәтен формалаштыру һәм оештыру тәҗрибәсен өйрәнү өчен менә дигән мөмкинлек бу», – ди министр.

Ел дәвамында республикада бу уңайдан барлыгы уннан артык чара узар дип көтелә. Алар турында тулырак мәгълүматны махсус сайттан (kazan.oicyouthcapital.com) табарга була. «Татарстан яшьләре ислам дөньясы илләре белән элемтәдә торырга тели. Быел Казанда уздырырга планлаштырылган чаралар турында тулы мәгълүмат тупланган махсус сайт эшләтеп җибәрдек. Татарстанда, Россиянең төрле төбәкләрендә һәм ислам дөньясы илләрендә яшәүче яшьләр шушы зур вакыйгаларның бер өлеше була алсын өчен эшләнде ул», – диде Татарстанның яшьләр дипломатиясе академиясе рәисе Дилбәр Садыйкова.

Сүзгә-сүз

«Татар-информ»

Илдус НӘФЫЙКОВ, Татарстан прокуроры:

Педагоглар тәрбия-профилактика эшчәнлегеннән читләште һәм бөтен җаваплылыкны әти-әниләргә күчерделәр. Ә аларның көче һәм вакыты, кагыйдә буларак, эшкә генә җитә. Нәтиҗәдә балаларны интернет һәм урам тәрбияли. Бу хәлне үзгәртергә кирәк. Моның өчен укытучының ролен һәм статусын күтәрергә кирәк. **(Татарстан Прокуратурасы утырышындагы чыгышыннан)**

Теманың дәвамы 2 нче биттә >

СТАНЦИЯЛӘРГӘ ИСЕМ САЙЛЫЙЛАР

Казанда метрополитенның икенче линиясенең яңа станцияләренә исем сайлау буенча сораштыруның икенче этабы уза. Тавыш бирү KZN.RU порталында уздырыла.

4 станциягә төзелеш барышында «Юлиус Фучик урамы», «10 нчы микрорайон», «ТАССРның 100 еллыгы» һәм «Академик Сахаров» дип вакытлыча исем бирделәр.

«ЮЛИУС ФУЧИК УРАМЫ»
ТАССРның 100 еллыгы / Имәнлек-2 / Кол Гали

«10 нчы МИКРОРАЙОН»
Ак. Завойский / 10 нчы микрорайон / Парк / Академия / Фәнни

«ТАССРның 100 ЕЛЛЫГЫ»
Азино / Дуслык / Чишмәле / Зилант

«ТАССРның 100 ЕЛЛЫГЫ»
Тулпар / Альберт Камалеев / Яратам

Утны күбрәк тотканнар

Быел гыйнвар аенда республика халкы һәм предприятиеләр 3,1 млрд кВт.сәгать күләмендә электр энергиясен кулланган. Узган елның шушы ук ае белән чагыштырганда 9,3 процентка күбрәк бу, дип хәбәр итә Төбәк диспетчерлык идарәсе матбугат хезмәте. Аерым алганда, автомобиль, химия сәнәгате, торбаүткәргеч транспорт, нефть эшкәртү заводлары һәм халык утны күп яккан.

Республикада энергия җитештерүче предприятиеләр узган елның гыйнвары белән чагыштырганда 6,3 процентка күбрәк электр уты (2,7 миллиард кВт.сәг.) эшләп чыгарган. Башлыча Казан ТЭЦ – 3, Зәй ГРЭСы, Чаллы һәм Түбән Кама ТЭЦлары җитештерүне арттырган. Электр энергиясенең җитмәгән өлеше катнаш энергетика системаларыннан алынган (гыйнвар аенда – 401,1 миллион кВт.сәг.).

zainsk-inform.ru



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ХӘЛИТКЕЧ КӨННӘР АЛДЫННАН

Дөньякүләм киеренкелек төсен алган Россия – Украина мөнәсәбәтләре бу атнада спиральнең яңа боҗрасын бөтерә башлады. Зур сугыш куркынычы берникадәр кимеде. Җитәкчеләр сөйләшүләр өстәле янында ешрак һәм озаграк утыра башладылар. Дүшәмбе Кремльдә Франция Президенты Макрон һәм Россия җитәкчесе Путин 6 сәгать сөйләште. Мәскәүгә килгәнче, француз Макрон Джо Байден һәм конфликтка кагылышы булган башка лидерлар белән дистанцион элемтәдә сөйләшүләр алып барды. Кремльдә зур овал өстәл янында бер-берсеннән бик ерак утырган ике җитәкче (коронавирустан шулай сакланалар) мәнфәгатьләрнең кисешкән урыннарын табарга тырыштылар. Каршы як Мәскәүнең компромисска баруын көтә, Путин даирәсе дә көнбатышлыларның чигенүен теләли. Шул ук вакытта килешү өчен нигезнең бик зәгыйфь булуын ике якта да аңлыйлар. Путин сүзчесе Песков әфәнде сөйләшү башланганчы ук: «Вазгыять артык катлаулы, бер очрашу барышында гына хәлиткеч үзгәрешләргә ирешерлек түгел», – дип белдерде. Шулай да сөйләшүдән соң алар үзләрен киеренкелекне йомшарту нокталары табылыр кебек тоттылар, әмма бер лидер да нинди уңышларга ирешелгәнлеген әйтмәде. Шулай да Франциянең АКШтагы илчесе Филипп Этьен The Washington Post газетасына: «Париж Мәскәүнең куркынычсызлык буенча тәкъдимнәрен кабул итәргә әзер түгел», – дип белдерде. Путин исә Макрон идеяләренең кайберләре өметле булуын искәртте. Мөгаен, Мәскәү компромисска барыр дигән ышаныч уята ул сүзләр, ләкин чигенүләр өчен мәйданның бик тар булуы да һәркемгә мәгълүм. Бу очрашуга һәм украин төененең ни рәвешле чишелешенә бөтен дөньяда зур әһәмият бирәләр. «Ватаным Татарстан» хәбәрчесе дүшәмбе көнне гарәп телле «Әл-Җәзира»ны карап утырды. Катар каналы, ничә ачсаң да, Макрон – Путин сөйләшүләрен төрләндерә, фронт сызыгына тезелгән гаскәрләрне төп сюжеты итеп ала иде.

Финанс базарлары Кремльдәге очрашуны уңай бәяләделәр: сум ныгыды, акцияләр салмак кына өскә күтәрелде. Украин «төен»е артында нәкъ менә базар тартышлары ята. Үткән тәүлекләрдә «газ сугышы»ның кискенләшүе билгеле булды. Россия ультиматум куеп, краннарны бер ябып, бер ачып уйнаган арада, Европа базарын америкалылар яулый башлаган икән. Сыек газ экспорты буенча АКШ дөньяда беренче урынга чыгып, пьедесталның өске басмасында ныгып маташа. Американнар, гыйнвар аенда рекордлы күләмдә газ сатып, Катарны узып киткәннәр. 2021 елда сыекландырылган газ сату буенча лидер Австралия булган, аннан соң Катар килгән. Америка өченче урында ныгыган. Базар белгечләре, 2022 ел бу өлкәдә хәлиткеч борылыш елы булачак, газга бәяләрне АКШ куячак, диләр. Сыекландырылган газ җитештерүче Америка компаниясе Venture Global LNG экспортка зур күләмдә ягулык сата башларга җыена. 2024 елда алар тагын яңа экспорт терминалларын сафка бастырырга телиләр. Кремль өчен бер дә яхшы хәбәрләр түгел бу. Байден: «Алдагы көннәрдә АКШ Европаның газга булган төп ихтыяҗларын канәгатьләндерә башлаячак, бу Мәскәүгә «авырттырып сугачак», – дип белдерде. Көнбатыш тупны Мәскәү капкасына ышанычлы итеп кертергә җыена. Кремль ничек җавап бирер, якын киләчәктә күрербез, Аллаһ теләсә.

Россиядә

САНКЦИЯЛӘР КАТЫ СУГАЧАК, ӘММА ГАЗНЫ КЫТАЙГА САТАРБЫЗ

Россиянең финанс базарындагы хәлне дә, импорт-экспорт сәясәтен дә Украина чигендәге киеренкелек билгели бүген. Фонд базарындагы гыйнвар мәтәлчеге Саклык банкы балансына бик каты суккан. Банктан ишетелгән хәбәрләр кыйммәтле кәгазьләр портфеленең 102,4 миллиард сумга юкаруын әйтәләр. Югалту күләме кредит оешмасының айлык табышыннан зуррак булган. Россиянең бөтен банк тармагы гыйнвар аенда 200 миллиард сум югалтты, дип бәяли Үзәк банк.

Россия компанияләре кырыс санкцияләр кертелеп, ил SWIFTтан мәхрүм ителсә, чит ил программалары белән тәэмин ителеш тукталса, чиплар һәм югары технологияле җиһазлар импорты өзелсә, ниләр буласын чамалау өчен өйрәнүләр үткәреп карадылар. Нәтиҗәләр турында беренче вице-премьер Белоусов җитәкләгән утырышта игълан ителде. Алар күңелле түгел. Россия базары андый вазгыятьне авыр кичерәчәк, югалтулар зур булачак.

Әлегә «кара алтын» базарында хәлләр Мәскәү файдасына. Украина чигенә танклар якынайган саен, Uralsның Европадагы бәясе күтәрелә, йөз долларга якынлаша. Россия Европага «кара алтын» озатуны бик нык киметте. Ил җитәкчелеге углеводородларны Кытайга сатуны арттыру турында җитди уйланалар. Көнбатышлылар белән хезмәттәшлек кыл өстендә тора бит. Чит ил аналитиклары нефть бәясе үскән саен, сугыш куркынычы да арта дип саныйлар. Алар моны Грузия белән 2008 елгы конфликтның һәм 2014 елгы Донбасс канкоешының «кара алтын» пигында оешуыннан чыгып әйтәләр.

Газ агымнарын да чин иле ягына бору планлаштырыла. «Российская газета»ның сишәмбе санында шул темага зур язма бар. Киләчәктә Кытайга 100 миллиард кубометр сыек ягулык озатылыр дип ниятләнә. Дөрес, әлегә аның кадәр газ куу өчен торбалар юк, сузасы бар. 2021 елда барысы 10 миллиард кубометр газ Кытайга барып җиткән. Хыялдагының уннан бер өлеше генә. Искә төшерик әле: «Себер куәте» дигән юан торбаны кайчан суза башладылар? 2014 елда. Сигез елга якын вакыт эчендә планлаштырылган куәтнең дүрттән бер өлеше генә сафка басты. 38 миллиард кубометрлык куәт бары тик 2024 елда гына тормышка ашырылачак. Тагын 60 миллиард кубометрдан артык газ куу өчен күпме торба сузарга, күпме акча сарыф итәргә туры киләчәген шуннан исәпләп була. Мәскәү, билгеле, Европа базарын да ташларга җыенмавын әйтә. Әмма ул тарафта барысы да катлаулы. Евросоюз диңгез аша Алжирдан да торба сузарга җыена. Испания шундый торбадан газ ала хәзер дә. Аны сузасы, дәвам итәсе генә кала. Чин иленә сузачак торбаларның коммерция килешүе дә төзелмәгән әле, ниятләр генә бар. Нефть базарындагы хәлләр дә ышанычлы түгел. Гарәпләр яңа «кара алтын» сугышы» башласалар, бәяләр түбәнгә сикерәчәк. Әлегә чүпрәләр сугыш куркынычында гына кабара.

АЧЫШНЫ ЭШЛӘТӘСЕ БАР

Татарстан Фәннәр академиясендә Россия Фәне көненә багышланган тантаналы җыелыш узды. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин республика галимнәрен һөнәри бәйрәмнәре уңаеннан котлады. Шулай ук гомуми җыелыш кысасында узган елга – Россия Президенты тарафыннан игълан ителгән Фән һәм технологияләр елына йомгак ясалды.

«Фән белән горурланырлыгыбыз бар, – диде парламент башлыгы, галимнәргә мөрәҗәгать итеп. – Тарихчыларыбызның, мәдәният, тел белгечләре, физик, химик, биолог, эколог, медикларыбызның исемнәре бөтен дөньяга танылган. Яшьләргә үрнәк булырга тиешле «алтын фондыбыз» бу».

Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, Фәннәр академиясенең уникаль социомәдәни проектлары зур әһәмияткә ия. «Матди һәм рухи культураны өйрәнү, тарихи-археологик өйрәнүләр, нефть химиясе өлкәсендә тикшеренүләр хаклы төстә Татарстан фәненең визит карточкасына әйләнде, – диде ул. – Республика бюджетына иң күп акча кертүче нефть-газ-химия һәм машина төзелеше предприятиеләренең, энергетика, агросәнәгать комплексларының өзлексез үсеше башлыча галимнәр белән иңгә-иң торып эшләүгә бәйле. Республикада төп предприятиеләрнең фәнни-тикшеренү институтлары белән хезмәттәшлеген саклап калуга ирешелде. Татарстанның күпкырлы икътисадында башкача була да алмый».

Шуңа да карамастан, парламент башлыгы билгеләп үткәнчә, фәнне үстерүдә моңарчы файдаланылмаган мөмкинлекләр дә бар әле. Әлегә фәннең социаль-икътисади үсешкә керткән өлеше җитәрлек түгел. «Фәнне җитештерүгә һәм җәмгыять тормышына җәлеп итүнең яңа мөмкинлекләрен эзләргә кирәк, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Безгә алга таба икътисадның төп тармакларында фәнни-мәгариф кластерларын үстерү юлыннан бару шарт. Бу өлкәдә академиянең республика вузлары, тармак институтлары һәм конструкторлык бюролары, сәнәгать предприятиеләре белән хезмәттәшлеген көчәйтү зарури».

Татарстан фәнгә булышуны дәвам итә: Фәннәр академиясенең фәнни тикшеренүләре башлыча бюджет акчасына башкарыла. Шул ук вакытта, Дәүләт Советы Рәисе әйткәнчә, фәнни идеяләрне акчалаштыру, инновацияләрне тизрәк гамәлгә кертү юлы белән бюджеттан тыш финанслауны да ныграк үстерергә кирәк.

Фәннәр академиясе президенты Мәгъзүм Сәлахов узган юбилей елын (Фәннәр академиясе төзелүгә – 30 ел һәм ТАССР Академия үзәге оешуга – 100 ел) республика галимнәре өчен уңышлы булды дип бәяләде. Әмма ул да фән һәм җитештерү арасында элемтәнең җитәрлек дәрәҗәдә тыгыз булмавын әйтте. Кадрлар мәсьәләсе дә көн үзәгендә тора.

tatarstan.ru

Татарстан Президенты Казан Кремлендә фән һәм техника өлкәсендә республика Дәүләт премияләрен тапшырды.

Татарстанда күп кенә тикшеренү оешмалары эшчәнлек алып бара, аларда 16 меңнән артык кеше эшли. Татарстанның югары уку йортлары һәм тикшеренү институтлары «Фән һәм университетлар» илкүләм проектының барлык чараларында да катнаша. Шуның аркасында республикада дөнья дәрәҗәсендәге яңа фәнни үзәкләр булдырыла, кадрлар яшәрә, җиһазлар яңартыла.

Президент фикеренчә, галимнәрнең эшчәнлеге кәгазьдә генә калмыйча, коммерцияле файда китерсен өчен икътисади шартлар да булырга тиеш. Әлеге бурычны хәл итү өчен республикада алдынгы инновацион экосистема корылган. Узган ел нәтиҗәләре буенча төбәкләрнең инновацион үсеше рейтингында Татарстан өченче урынны алды. «Алда дөнья дәрәҗәсендәге кампус һәм алдынгы инженер мәктәпләре булдыру, университет технологик эшкуарлыгына ярдәм итү, башка проектлар белән бәйле зур планнар бар», – диде Рөстәм Миңнеханов. Татарстанның озак вакытка исәпләнгән фәнни-технологик үсеш стратегиясен әзерләүгә дә зур игътибар биреләчәк.

29 кеше фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Дәүләт премиясе лауреатлары булды. Бүләкләр түбәндәге хезмәтләр өчен тапшырылды:

- балаларда йөрәк-кан тамырлары авыруларын алдан диагностикалау өчен инновацион технологияләрне эшләү һәм гамәлгә кертү (КДМУ);
- «Радиодулкыннарның һәм атмосферада дулкын процессларының метеор-оносфер таралуы» эшләр циклы (КФУ);
- Татарстан Республикасында селекция казанышлары – татар токымлы атларны булдыру һәм куллану (Н.Э. Бауман исемендәге КДВМА);
- Ромашкино ятмаларын соңгы стадиядә эшкәртүнең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында нефть чыгаруны интенсификацияләү буенча технологик карарлар комплексын гамәлгә ашыру («Татнефть» ГАҖ).

Челтәргә игътибар кирәк

Нәтиҗә

Узган елда прокуратура органнарына халыктан 96 меңнән артык мөрәҗәгать кергән. Ведомство хезмәткәрләре 10 меңнән күбрәк закон бозу очрагын ачыклап, тиешле чаралар күргән. Бу хакта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов прокуратура коллегиясе утырышында белдерде. Коллегия прокуратураның узган елдагы эш йомгакларына һәм быелгы бурычларына багышланды.

Россия генераль прокуроры урынбасары Николай Шишкин белдергәнчә, республикада җинаятьләрне ачу күрсәткеченең кимүе күзәтелә. Идел буе федераль округында әлеге күрсәткеч уртача 54,3 процент тәшкил итсә, республика буенча 45,6 процент кына. Николай Шишкин акча яки башка мөлкәтне «юу»га бәйле җинаятьләрне ачыклау эшенең нәтиҗәсезрәк булуын искәртте. Быел бары тик 9 шундый җинаять исәпкә куелган. Шул ук вакытта округ буенча бу сан – 220, ил буенча – 923. Моннан тыш ул прокуратурага өлешчеләр, хезмәт хакын вакытында түләмәүчеләр буенча, кешеләрнең торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге хокукларын, эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча эшне көчәйтергә кушты.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов коллегия барышында ведомство хезмәткәрләренең республика законнарын үтәтү, кешеләрнең проблемаларын хәл кылу буенча зур эш башкаруын билгеләп үтте.

– Республика прокуратурасы килеп туган катлаулы шартларда үз бурычларын сыйфатлы башкарды. Халыкның прокурорларга ышанычының югары дәрәҗәдә булуын билгеләп үтәсем килә, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Президент ветераннар, инвалидлар, пенсионерлар һәм балигъ булмаганнарны яклауның аерым игътибар үзәгенә алынуын басым ясап әйтте. Аның сүзләренә караганда, прокурор чаралары ярдәмендә дистәләрчә мең кеше хезмәт хакын алуга, бушлай торакка, даруларга яки матди яктан тәэмин ителүгә хокукларын торгыза алган. Эшмәкәрләр белән эшләүгә килгәндә, Рөстәм Миңнеханов алга таба да административ киртәләргә каршы көрәшүне дәвам итүнең, бизнеска үсәргә комачауламауның мөһимлеген искәртте. «Кызганыч, узган елда мәгариф оешмаларының иминлеге өлкәсендә җитди проблемаларны фаш иткән фаҗига булды. Прокурор тикшерүләре бу өлкәдә йөзләрчә кимчелекне ачыклады. Бүгенгә без уртак тырышлык белән шуларның күпчелеген юкка чыгару мөмкинлеген таптык», – дип искә төшерде Татарстан Президенты. Ул алга таба да әлеге проблеманы күз уңыннан ычкындырмауны сорады.

– Шулай ук интернет челтәрендә җәмгыятьтәге хәлләрне тотрыксызландыруга юнәлдерелгән ялган мәгълүматларны ачыклау буенча кыю төстә эш итәргә кирәк. Кешеләрнең сәнәгатьтә иминлеге, өйдә газ җиһазларыннан файдаланудагы иминлек тә зур игътибар таләп итә, – дип белдерде Рөстәм Миңнеханов.

Президент, утырышка йомгак ясап, узган елдагы кыенлыкларга карамастан, Татарстан прокуратурасының чираттагы тапкыр үзен нәтиҗәле орган буларак күрсәтүен әйтте.

Телефоннан бер дәшүең җитә...

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Бу акчага дәгъва кылу өчен алданган кеше банк тарафыннан операциянең уңышлы башкарылуы турында смс-хәбәр килгәннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча банкка кырыгалдар тарафыннан алдануын хәбәр итәргә тиеш.

Рәсми саннардан аңлашылганча, узган ел ил халкы мошенникларга барлыгы 45 миллиард сум акча күчергән. Банклар исә бу сумманың 300 миллион сум чамасын гына кире кайтарган. «Телефон аша алдану очракларының артуына үзебез дә гаепле. Акыллы кеше ниндидер билгесез затка телефон аша үзенең исәп-хисап счетын, банк картасы артындагы яшерен өч санны әйтмәячәк, билгеле. Хис-кичерешләр белән түгел, акыл белән эш итәргә кирәк. Кырыгалдар белән сөйләшергә теләмичә трубканы куйган өчен берәү дә авызыңа сукмаячак бит», – ди юрист Роман Архипов.

Арабызда аек акыллылар да җитәрлек анысы. «ПромРейтинг» агентлыгы тарафыннан уздырылган соңгы сораштыру нәтиҗәләрен генә алыйк. Шушы тикшеренүдә катнашкан респондентларның 60 проценты телефонга шалтыраткан таныш булмаган номерларны бөтенләй алмавын әйткән. Һаман да шул кырыгалдарлар тарафыннан алданмас өчен, билгеле. Әмма шуннан ары да төп башына утыручылар табыла.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ – ТӨЗҮЧЕЛӘРГӘ:

«ХАЛЫК ТУРЫНДА УЙЛЫЙК»

Төзелеш

Узган ел республикада торак төзү буенча рекорд куелган. Планлаштырылган 2 миллион 670 мең квадрат метр урынына 3 миллион 11 мең 451 квадрат метр торак төзелгән. Шуның 2 миллион квадрат метры шәхси торак төзелешенә туры килә. Республикада 15329 йорт төзелгән. Былтыр Татарстан алданган өлешчеләр проблемасын хәл итү буенча да Россиядә беренче урынга чыккан. 9 йортта 450 гаилә өчен фатир төзелеп тапшырылган. 2021 елда төзүчеләр пандемиягә кадәрле вакытта эшләнелгән эш күләменә кайтканнар. Бу хакта Татарстан Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының еллык киңәйтелгән утырышында әйтелде.

– 2021 елда торак төзү артып киткәч, төзелеш материаллары җитештерүче оешмалар да эшкә күмелде. Ел дәвамында 45,3 млрд сумлык товар җитештерелде. 2020 ел белән чагыштырганда, төзелеш материалларына ихтыяҗ 8 процентка артты, – диде төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин.

Министр төзелеш өлкәсендәге республика һәм федераль программаларга да тукталды. 2021 елда бу программалар ярдәме белән 1 меңнән артык объект төзелгән һәм яңартылган. Әлеге максатларда 5 млрд 764 миллион сум акча тотылган.

– 2024 елга Казандагы биологик чистарту корылмаларын төзекләндереп бетерергә планлаштырабыз. Әлеге эш «Иделне савыктыру» федераль программасы ярдәме белән тормышка ашырыла. Шулай ук Татарстандагы 79 калдык суларны агызу системасына да ремонт кирәк. Быел аларның 18ендә яңарту эшләре башланачак. Моның өчен республика бюджетыннан 500 миллион сум акча бирелә, – дип санап үтте министр.

Тик чистарту корылмаларын куллану өчен белемле хезмәткәрләр кирәк. Бу проблеманы район хакимияте вәкилләре һәм ресурс белән тәэмин итүче оешмалар белән бергә хәл итәргә кирәк. Төзелеш тармагында да кадрлар җитми. Эшче кулларга кытлык. Әлегә бу проблема чит ил гражданнары исәбенә хәл ителә. «Төзүче һөнәренә хөрмәтне арттырырга кирәк. Былтыр төзелештә читтән килгән 28180 кеше эшләде», – диде министр.

Цифрлаштыру елы уңаеннан башкарыласы эшләргә килгәндә, министрлыкта электронлаштыру инде 2021 елда ук башланган. Узган ел төзелеш өлкәсендә социаль әһәмияткә ия 46 хезмәтнең тугызын электрон вариантка күчергәннәр. Быел калганнарын да күчереп бетерәчәкләр. Республикада төзелеш тармагы экосистемасының бердәм цифрлы системасын булдырырга ниятлиләр. Шулай ук быел төзелеш, капиталь төзекләндерү буенча 44 республика программасы һәм 7 илкүләм проектын гамәлгә ашыру дәвам итәчәк.

Татарстан Президенты карары буенча 2022 елда авыл җирлекләрен сыйфатлы су белән тәэмин итү өчен бирелгән акча күләме ике тапкыр арттырылган. Элек 650 миллион сум булса, хәзер су кертү өчен 1 млрд 300 миллион сум акча тотылачак. Димәк, ниһаять, күп кенә авылларга чиста су килеп җитәр дигән өмет бар.

Министр үз чыгышында, торак-коммуналь хезмәт күрсәтүче оешмаларның ресурс белән тәэмин итүчегә булган бурычларын киметүгә ирештек, дип белдерде.

– 2021 ел башына 610 миллион сум бурыч бар иде. Без аны 41 миллион сумга киметтек. Халыкның исә торак-коммуналь оешмаларына 8 млрд сумга якын әҗәте бар. Әмма шунысын да әйтергә кирәк: соңгы берничә елда квартплата өчен акча җыю 98 проценттан төшми. Түләүләрнең 68 проценты электрон рәвештә башкарыла. Бу яктан без Россиядә алдынгы булып торабыз, – диде министр. – Халыктан бурычларны җыю – идарәче оешманың бурычы, киләчәктә, район хакимияте һәм идарәче оешмаларга бергәләп эшләргә кирәк, – дип искәртте ул.

Утырышта катнашкан Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов быел республикада төзелгән торак өчен төзүчеләргә рәхмәтен җиткерде.

– Бу – зур хезмәт. Төзелеш тармагында эшләүче һәр кешегә рәхмәтемне җиткерәм. Сез урам, парк, ишегаллары, юллар, йортлар төзеп, халык күңелендә яхшы фикер калдырырга тиеш, – диде ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Аннары инде кайбер проблемаларга тукталды.

– Төзүчеләр, фатир алучыларга процент ставкаларын күтәрергә кирәк, дисәләр дә, моны эшләми торыйк. Фатирны йә торыр җире булмаган, йә инде торак шартларын яхшыртырга теләгән кешеләр сатып ала. Халык турында уйлыйк, – диде Президент.

Рөстәм Миңнеханов төзүчеләргә йорт салуны гына түгел, документ эшләрен дә тәртиптә тотарга һәм алдан эшләргә кушты. 2023 елда башкарасы эшләр хакында быелның апрель аена хисап әзерләргә, параллель рәвештә 2024 ел турында уйларга кирәк, диде.

– Йортларны капиталь төзекләндерүгә тукталасым килә. Әгәр йортта яшәүчеләр подрядчы оешманың эш сыйфатыннан риза түгел икән, алар аннан баш тартырга хокуклы. Шуңа да ремонт ясаучы оешмаларны контрольдә тотарга кирәк. Торак инспекциясе эшне күзәтүне көчәйтергә тиеш, – диде Президент.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

САТУ УРЫННАРЫ ӨЧЕН... 1 сум

Агросәнәгать

Фермерлар белән еш очрашырга туры килә. Шундый аралашулар вакытында җитештергән продукцияләрен сату белән бәйле авырлыклар турында да ишетәбез. Зур кибетләр челтәренә үтеп керә алмау, гадел булмаган көндәшлек, сату мәйданнарының артык кыйммәт һәм тикшерүләрнең катлаулы булуы. Авыл хуҗалыгы тармагында эшләгән һәркемгә таныш авырлыклар бу. Менә шундый җитештерүчеләр өчен күңелле яңалык килеп иреште.

«Казан» агросәнәгать паркы аграрийларга сату нокталарын нибары... 1 сумга тәкъдим итә. Комплексның генераль директоры Олег Власов сүзләренә караганда, әлеге акция 15 февральдән 15 мартка кадәр дәвам итәчәк.

– Без бу акцияне ел саен үткәрәбез һәм ул моңа кадәр комплекста булмаган авыл хуҗалыгы җитештерүчеләрен җәлеп итәр өчен уздырыла. Аның максаты безнең өчен бик мөһим. Беренчедән, үзебезнең җитештерүчеләргә ярдәм итү һәм аларның продукцияләрен сату мәйданнарын арттыру булса, икенчедән, сатып алучыларга сайлап алырга мөмкин булган табигый ризыклар ассортиментын киңәйтү. Авыл хуҗалыгы тармагында эшләүчеләргә болай да җиңел түгел. Аларга ярдәм итә һәм комплекста яңа эш урыннары ача алсак, максатыбызга ирешер идек, – ди Олег Власов.

Җитәкче аңлатуынча, әлеге бәягә сату урыныннан тыш, кирәкле барлык җиһазлар (суыткыч, шкафлар һәм башкалар), шулай ук Татарстанның Баш ветеринария идарәсеннән бүләк буларак, ветеринар контрольне бушлай уздыру керә. Сатучылар ризыкларга санитар экспертизаны заманча җиһазларда уздыра алачак. Болардан кала, акциядә катнаша торган барлык ит, балык һәм сөт продукциясе ветеринар-озату документын бушлай алачак.

Әлеге акциядә фермерлык кооперативлары, фермер хуҗалыклары, шәхси хуҗалыклар һәм башка авыл хуҗалыгы оешмалары катнаша ала. Моның өчен аларга «Казан» агропаркына әлеге статусны дәлилли торган документлар тапшырырга, килешү төзергә кирәк булачак.

– Әлеге вакытта акциядә агропарктагы 26 урын тәкъдим ителә. Бер сәүдә урыны бер кешегә генә бирелә. Билгеле, бу урыннар саны көн саен үзгәреп тора. Акция белән кызыксынучылар күп. Шуңа күрә аның турында тулы мәгълүматны 8 (843) 237-64-34 телефон номерына шалтыратып белешергә мөмкин, – ди Олег Власов.

Аның сүзләренә караганда, акция бер ай дәвам итәчәк. Ләкин вакытлары үзгәрергә дә мөмкин булуын искәртте.

Иң зур сату мәйданнарының берсе булган парк директоры әйтүенчә, узган ел бирегә йөрүчеләр саны бераз кимегән. Мәсәлән, 11 айда агропаркка 1 млн 640 мең кеше килгән. 2020 ел белән чагыштырганда, күрсәткечләр 1,5 процентка кимрәк.

– Сатып алу мөмкинлекләре кимү аркасында, халык базарга һәм кибеткә азрак йөри башлады. Ләкин узган елгы үзгәрешләргә карамастан, агросәнәгать паркы сәүдә мәйданнарын яхшырту буенча башлаган эшләрдән тукталмады. Мәсәлән, «Индюжина», «Деревенские продукты» һәм «Мясо птицы» мәйданчыклары формалашты һәм җиһазландырылды. «Норд ФИШ» дип аталган сәүдә урыны булдырылды. Биредә төньяк диңгез балыклары деликатеслары сатыла. Шулай ук кулланучыларга итне өстәмә турау һәм эшкәртү буенча яңа төр хезмәтләр тәкъдим ителә башлады. Мондый чаралар халыкны җәлеп итәргә, ихтыяҗ азрак булган сәүдә зоналарын киметергә һәм сәүдә залларын гомумән мәгълүмати һәм матур итәргә мөмкинлек бирде, – дип саный Олег Власов.

Гомумән, илдәге икътисади вазгыять агропарк резидентларына да йогынты ясамыйча калмаган. Халык аз йөргәч, аларның да керемнәре кимегән. Ләкин икътисади күрсәткечне 2020 елгы дәрәҗәдә саклап калыр өчен, җитәкчелек мөмкин булган барлык чараларны да куллана.

Олег Власов билгеләп узганча, бүген комплекста 236 резидент үз товарын тәкъдим итә һәм 1 мең тирәсе кеше эшли. Узган елның ун ае эчендә сату мәйданында товар әйләнеше 1,8 млрд сумны тәшкил иткән, сатып алучының уртача чегы 1300 сум булган. 2020 ел белән чагыштырганда, әлеге күрсәткечләр 18 процентка артса да, 2019 елга караганда 5 процентка кимрәк булган.

– Кулланучылар базарындагы хәлләрне искә алып, без узган ел башында күпләп сату юнәлешен тагын да арттыру өстендә эшли башладык. Дөрес кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә бу юнәлештә уңышка ирештек һәм алга таба да әлеге эшне дәвам итәргә уйлыйбыз, – диде Олег Власов.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

Стипендиянең артыгы юк

Белем һәм тәрбия

Тиздән студентлар өчен яңа стипендия булдырылачак. Халыкара бәйгедә җиңгән укучыларга грантлар, вузга укырга кергәндә ташламалар каралса да, студентларга андый мөмкинлекләр әлегә юк инде. Владимир Путин Россия фән һәм югары белем бирү министры Валерий Фальковка: «Саранланмыйк!» – диде. Министр стипендия күләмен әйтмәсә дә, лаеклы булачак, дип ышандырды.

Укучылар турында

Татарстанда халыкара математика, физика, химия, биология, информатика, география һәм башка олимпиадаларда алтын медаль алучы укучыларга – 150, көмеш өчен – 100, бронза медаль ияләренә 75 мең сум акча бирелә. Аларны бәйгегә әзерләгән укытучыларга моның яртысы түләнә. Әйтик, Мәскәүдә беренче урын алучыларга бу сумма – 1 миллион, икенче урынга – 750, өченчегә 500 мең сумны тәшкил итә. Укытучыларны да шундый ук күләмдәге акча белән бүләклиләр.

Узган ел 8–10 сыйныф укучылары «Озын тәнәфес» Бөтенроссия конкурсының финалында катнашып, шактый гына акча эшләп алган иде. Әйтик, Әгерҗе шәһәрендәге 4 нче мәктәпнең 11 нче сыйныф укучысы Никита Филиппов 1 миллион сум акча отты. Никита мәктәпне тәмамлагач, Мәскәү яки Санкт-Петербург вузларына укырга керергә хыяллана. Дөресрәге, анда мөмкинлекләр күбрәк дип саный.

– Стипендия студентлар өчен бик мөһим. Аны белемгә, ниндидер яңа өлкәне өйрәнү өчен гаджетлар сатып алуга тотарга мөмкин. Дәүләт тә яшьләр белән кызыксына. Ачышлар ясаган акыллы кешеләрне илдә һәрвакыт югары бәяләгәннәр. Күп нәрсә олимпиада, бәйгеләрдән башлана дип уйлыйм. Мондый уңышлар студентка гына түгел, җәмгыять өчен дә файдалы. Үзем дә күп кенә бәйгеләрдә катнашып, җиңүләр яуладым. Сәләтле балаларга түләүләр мәктәптән үк булдырылсын иде. Бу – тырышып укыр өчен яхшы этәргеч, – ди Никита Филиппов.

Студентлар турында

БДИда 399 балл җыеп, бүген КФУның 3 курсында белем алучы Казан егете Рамил Баһаветдиновның да фикерен белештек.

– Мондый стипендияләрнең артыгы юк, чөнки алар укуда өстәмә этәргеч бирә. Әгәр стипендиянең күләме дә җитәрлек икән, бу тагын да яхшы, югыйсә күп очракта студент өстәмә керем турында уйларга мәҗбүр, укуга үзен тулысынча багышлый алмый. Хәзерге вакытта бу юнәлештә эш алып барыла, төрле грантлар тәкъдим ителә, ләкин һәркайда да кешеләр канәгатьме, юкмы икәнен әйтә алмыйм, үз университетым турында гына беләм. Бездә төрле өлкәдә уңышка ирешкәннәргә өстәмә стипендия алу мөмкинлеге бар, уку алдынгылары исемле стипендияләргә лаек була, – диде Рамил.

Татарстан Цифрлы үзгәртеп кору үзәгенең ИТ-проектлар координаторы, КФУ студенты Тимерхан Шәйхетдинов әйтүенчә, вузда халыкара бәйгеләрдә откан яшьләр өчен андый бәяләү каралмаган. Олимпиада, ярышларда җиңүләрне, югары яки башка стипендия алганда, портфолио итеп кулланырга мөмкин. Барысын җыйсаң, билгеле бер балл өстәлә. Әйтик, югары дәүләт стипендиясе, транспорт грантын һәм башкаларны алырга мөмкинлек бирә.

– Студентларга мондый стипендия бик кирәк. Бүгенге вазгыятькә күз салсак, алар арасында әти-әниләре еракта яшәүчеләр, чит төбәкләрдән килүчеләр бар. Фатирда, тулай торакта яшәгән өчен түләргә кирәк. Студентлар мөстәкыйль булырга тырыша. Бәяләр күтәрелеп тора, стипендия артмый. Шуның өчен эшкә урнашу җаен эзлиләр. Анда да бит әле күпме түлиләр... Студентка акча һәрвакыт кирәк. Сәләтлеләр югары стипендия алса да, ул күп очракта бер генә мәртәбә бирелә. Халыкара олимпиадаларда җиңүчеләр өчен дә, тагын башка күп төрле стипендияләр булсын. Моны студент буларак әйтәм. Әгәр студентның башында эш, акча табу мәшәкате генә булса, аның дөньяны өйрәнергә вакыты калмас, – ди Тимерхан Шәйхетдинов.

Сәрия МИФТАХОВА

ЯЗЫН – ЙӨГЕРӘСЕ, ҖӘЕН – ЙӨЗӘСЕ

ТАТАРСТАНДА НИНДИ СПОРТ ЧАРАЛАРЫ КӨТЕЛӘ?

Татарстанның спорт министры Владимир Леонов: «Безгә хәзер ышаналар», – дип кабатларга ярата. Әйтүе рас килә. Күп кенә халыкара спорт чараларын үткәрү урыны итеп нәкъ тә Татарстан һәм башкаланы сайлаулары шуның бер дәлиледер. Хыялда исә – Җәйге Олимпиада. Тик... яшьләрнеке.

Хөкүмәт йортында журналистлар белән узган очрашу вакытында республиканың спорт министры Владимир Леонов быелга тәгаенләнгән спорт чаралары турында сөйләде. Исемлек озын. Кайсыларында спортчылар гына түгел, халык та катнаша ала әле.

Министр искәрткәнчә, соңгы 10 елда спорт чараларын үткәрүдә Татарстан башкаласы үз йөзен булдырды. Шуңа да ышаналар, халыкара ярышларны оештыру урыны итеп нәкъ тә республиканы күрәләр.

Быел йөзү буенча ярышлар күп булачак. Августта Казанда яшьләр (юниорлар) арасында йөзү буенча FINA дөнья беренчелеге узачак. 120 илдән 850 спортчы килер дип көтелә. Министр моның зур ярыш булуын искәртте. 2025 елга билгеләнгән йөзү буенча дөнья чемпионатына әзерлек буларак та кабул итәргә ярый аны. Моннан тыш, суга сикерү, синхрон, кыска сулыкта йөзү буенча ярышлар узачак. Ә менә көзен оештырылырга тиешле йөзү буенча дөнья кубогы ярышын башка вакытка күчерергә дә мөмкиннәр. Кыска сулыкта йөзү ярышлары исә, һичшиксез, узачак. 180 илдән бер меңнән артык спортчы килер дип көтәләр. Анысы 17–23 декабрьдә узачак.

Судан җиргә чыксак, июльдә «Урам» паркында узачак Илкүләм урам уеннары чарасын, августта регби-7 буенча студентлар командалары арасында дөнья кубогы ярышын телгә алдылар.

Моннан тыш, спортчылар гына түгел, спортка битараф булмаганнар да катнаша алырлык чаралар көтелә. Владимир Леонов «Timerman» кысасында йөгерү марафоны, велосипедта ярыш, ярыммарафон, триатлон кебекләрен атады. Кайсылары Әлмәттә оештырылачак. Бу чаралар сериясе майдан башланып октябрьгә кадәр дәвам итәчәк.

Очрашу Олимпия Уеннары гөрләгән чорга туры килгәч, әлбәттә, үзебезнекеләр турында да сүз булмый калмады. Әйтик, министр Камилә Вәлиеваны мактады, мондый кызны тәрбияләп үстергән ата-анасына рәхмәтен җиткерде. Данил Садриевның көтелмәгән уңышына сөенде. Сноубордчы Виктор Уайлдны да мактамый хәл юк. Олимпия Уеннарындагы җиңүеннән соң карьерасына нокта куйган спортчыга «Почетлы гражданин» исемен бирү турында тәкъдимне җитәкчелеккә җиткерәсен әйтте. Кыскасы, зур ярышта ил данын яклаган Татарстан спортчыларына рәхмәт әйтү кул кысышу белән генә чикләнмәячәк.

Олимпиада димәктән, әлегә Татарстан мәртәбәле чараның яшүсмерләр арасында уза торганына гына үрелә ала.

– Яшүсмерләр арасында Олимпия уеннарын кабул итү теләге бар, без аларны үткәрергә сәләтле, корылмалар ягыннан да без әзер. Бу хакта Россиянең спорт министры белән дә сөйләштек. Әмма, кызганыч, вазгыятьне беләсез, безнең агымдагы ел азагына кадәр нинди дә булса гаризалар тапшыруга бәйле чикләүләр бар, – диде ул.

Теманың дәвамы 4 нче биттә >

КОТЛЫЙБЫЗ!

Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсе дәүләт геология күзәтчелеге бүлеге башлыгы **Зәйнуллин** Илһам Гатият улына **«Татарстан Республикасының атказанган геологы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Казан шәһәренең «7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы **Делян** Артур Марковичка **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Рәссам-график, «Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге» төбәк иҗат иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Гаимов** Рәшит Хәмит улына **«Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Республикада экологик куркынычсызлыкны һәм әйләнә-тирә мохитне саклауны тәэмин итүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсе җитәкчесе урынбасары **Гайнетдинова** Лилия Әхәт кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының халыкара абруен ныгытуга зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Россия Федерациясе сенаторы Федерация Советының Халыкара эшләр буенча комитеты рәисе урынбасары, «Россия – ислам дөньясы» стратегик караш төркеме рәисе урынбасары **Мөхәммәтшин** Фәрит Мөбарәкша улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Республиканың җылылык-энергетика комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте генераль директоры урынбасары – җәмгыятьнең техник директоры **Гайфуллин** Илгизәр Хәбир улы; республиканың социаль-икътисади үсешенә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасы башкарма директоры **Зарипов** Марат Ривгать улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

Гаражларны тәртипкә китерәләр

2021 елның 1 сентябрендә «Гараж амнистиясе турында»гы Закон гамәлгә кергәннән бирле, 4 ай эчендә Татарстанда 800гә якын күчемсез объект теркәлгән һәм республика лидерлар исемлегенә кергән. Шулай ук бу эштә Мордовия Республикасы, Тверь, Түбән Новгород өлкәләре алда бара. Россия буенча теркәлгән гаражларның саны 10 мең тирәсе.

– «Гараж амнистиясе турында»гы Законны тормышка ашыру республикабызда актив башланып китте, – ди Татарстан буенча Росреестр идарәсе җитәкчесе Азат Җәббаров. – Идарәгә килгән документлардан күренгәнчә, халык бу закон белән бик кызыксына, корылмаларны вакытында тәртипкә китереп калырга тырыша. Үзебез дә аңлату эшләрен туктатмаска тырышабыз. Аңлашыла ки, «гараж амнистиясе»н тормышка ашыруда хәлиткеч рольне җирле хакимият үти, чөнки халык беренче чиратта аларга мөрәҗәгать итә.

Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестры мәгълүматларына караганда, Татарстанда бүген хокуклы ияләре булмаган 40 меңгә якын гараж бар әле. 2026 елның 1 сентябренә кадәр гамәлдә булачак закон аларга бу милекнең чын хуҗасы булырга ярдәм итәчәк. Әлеге документ нигезендә гаражны рәсмиләштерү бик гади. Моның өчен гражданнар беренче чиратта җирле үзидарә органнарына (шул исәптән күпфункцияле үзәккә) гаражны һәм ул урнашкан участокны рәсмиләштерү өчен гариза язарга тиеш. Тик аның белән бергә гаражның хуҗасы икәнен расларлык берәр документ та таләп ителә. Бу, мәсәлән, гараж кооперативында пай түләү турындагы документ, кайчандыр гараж бирелү турындагы карар, техник инвентарьлаштыру турындагы элегрәк тапшырылган документлар булырга мөмкин. Шунысын да искәртү урынлы: барлык гаражлар да амнистиягә эләкми. Бу закон – Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы гамәлгә кергәнче, ягъни 2004 елның 31 декабренә кадәр салынган гаражлар өчен генә. Монда да сүз нигезе һәм стенасы булган капиталь корылмалар турында бара. Алар бер катлы, торак өчен тәгаенләнмәгән булырга тиеш. Гараж кооперативлар составына керергә дә, аерым урында төзелгән булырга да мөмкин. Ул урнашкан җирнең дәүләтнеке булуы шарт. Үз белдеге белән салынган, күпкатлы йортлар һәм офис комплексларында урнашкан җир асты гаражлары амнистиягә эләкми. Теркәлгән милекне мирас итеп калдырырга да мөмкин булачак.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

Спорт

ТАТАРСТАННЫҢ ТРАМПЛИННАН СИКЕРҮ ФЕДЕРАЦИЯСЕ БАШЛЫГЫ ӘНӘС ВӘЛИЕВ:

«Данилдан медаль өмет итмәдек»

instagram.com

Киемеңә карап каршы алалар, медалеңә карап озаталар. Россия чаңгы белән трамплиннан сикерүчеләренең Олимпиаданың катнаш команда ярышларында икенче урынны алуы тарихи вакыйга булды. Көмеш медаль ияләре арасында Татарстаннан 18 яшьлек Данил Садриев та бар. Безнекеләр үзләре дә тырышты, көндәшләр дә нык ярдәм итте.

Көтелмәгән вакыйга!

Владимир Белоусов турында спортны бик нык күзәткән кешеләр генә белә булыр. 1968 елда Гренобльдә узган Олимпия Уеннарында чаңгы белән трамплиннан сикерү ярышларында чемпион булып танылган ул. Шуннан бирле СССР һәм Россия спортчылары бу төрдә бер мәртәбә дә медаль ота алмаган. Дүшәмбе көнне исә безнекеләр икенче урынны яулады. Ирина Аввакумова, Ирма Махиня, Евгений Климов һәм Лениногорскидан 18 яшьлек Данил Садриев катнаш команда ярышларында көмеш медаль эләктерде. Көтелмәгән вакыйга!

Чөнки безнекеләр фаворитлар исемлегенә керми. Ә дүшәмбе көнне хөкемдарлар лидерга каршы «ау» игълан итте. Кагыйдә буенча, спортчының костюмы аның тәненә сыланып диярлек торырга тиеш. Кабарган кием белән ярышка кертмиләр. Шуның аркасында Алмания, Япония, Австрия һәм Норвегия сикерүчеләренең нәтиҗәләрен исәпкә алмадылар. Мондый хәлләрнең элегрәк тә булганы бар иде, әмма берьюлы бу кадәр команданың җәзага тартылганын белгечләр дә искә төшерә алмый. Россия спортчылары бу хәлдән бик яхшы файдаланды һәм Словениядән калышып, икенче урынны алды. Безнекеләр дә тырышты, хөкемдарларга да рәхмәт!

Энесе абыйсын уздырды

Мондый нәтиҗәгә иң сөенгән кешеләрнең берсе якташыбыз Данил Садриев булгандыр, мөгаен. 18 яшьлек егет Пекиннан көмеш медаль алып кайтыр дип кем уйлаган? «Әлбәттә, сенсация. Медальгә әзер идем, әмма болай булыр дип уйламадым», – дигән ул Пекинда журналистларга.

Татарстанның трамплиннан чаңгы белән сикерү федерациясе башлыгы Әнәс Вәлиев тә яшерми, Данилдан медаль өмет итмәгәннәр.

– Данил үсә, күрсәткечләре яхшыра, нәтиҗәне исә киләсе Олимпиададан көттек. Ул – Лениногорскидан Олимпиадага барган өченче егетебез. Моның белән бик горурланабыз. Әмма 1998 елда Николай Петрушин да, моннан 8 ел элек Иван Панин да ярышларда беренче 40 спортчы арасына керә алмады. Бу бала 30лыкка керсә, Лениногорск өчен зур уңыш булыр – Данил Олимпиадага киткәндә шулай дип уйладым, – ди Әнәс Вәлиев. – Ә ул шәхси ярышта 8 нче урынны алды. Инде монысы ук безнең өчен гадәттән тыш вакыйга булды! Шәхси ярышларда Климов – 5 нче, Аввакумова – 7 нче, Махиня 10 нчы урынны алды. Күрәсезме, дүртесе дә унлыкка кергән, димәк, тигез команда. Кем әйтмешли, бөтен йолдызлар бер сафка тезелеп басса, бронзага үрелә алабыз дип уйладым. Шулай килеп чыкты да! Хәзер нәрсә сорыйсыгызны да беләм. Көчле көндәшләрне ярыштан төшереп калдыруның ярдәме булдымы? Бу – аларның проблемасы. Спортчыларның костюмнары бик нәзберек мәсьәлә ул. Андый хәлләр булгалый. Әмма Олимпиадада берьюлы дүрт команданы ярыштан чыгарганнары юк иде әле. Әйе, гадәттә кырыс чаралар безнекеләргә каршы күрелә. Моңа әзер тордык.

Данил Садриев узган ел Лениногорскиның 8 нче мәктәбен тәмамлаган. «Бу мәктәп җитәкчелегенә рәхмәт әйтми мөмкин түгел. Спорт белән шөгыльләнүчеләргә ярдәм итәләр анда», – ди Әнәс Вәлиев. Хәзер исә егет Стәрлетамактагы спорт колледжында белем ала.

Данил – кечкенәдән үк авырлыклар күреп, язмыш сынаулары аша узып үскән егет. Абыйсы Марс белән балалар йортында тәрбияләнгәннәр. Тренерлары Николай Герасимов кулына башта Марс килеп эләгә. Аннары аңа ияреп кечкенә Данил килә. Икесе дә трамплиннан сикерү белән мавыгып китәләр. Дөрес, абыйсы төп игътибарны укуга биреп, спорттан китеп тора. Әмма ике елдан кабат әйләнеп кайта, ул – да спорт остасы, Татарстан җыелма командасы вәкиле. Әмма Данилга ераграк һәм биегрәк сикерергә насыйп булган.

P.S. Сноубордчы Виктор Уайлд Пекин Олимпиадасында параллель гигант слалом ярышында өченче урынны яулады. АКШта туып-үскән Виктор Уайлд 2012 елда Россия гражданлыгы алды. 2014 елда Сочида узган Олимпия Уеннарында ул ике мәртәбә чемпион исемен яулады. 2019 елдан 35 яшьлек сноубордчы Татарстан спортчысы булып санала.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

ТЫЕЛГАН ҖИМЕШ АЧЫСЫ

Без әле кая барабыз?

Начар үрнәк тиз йога, ди. Әле ул үрнәк тирә-юньдә түгел, виртуаль чынбарлыкта, китаплар дөньясында, колакчыннарда булса, кешене көн дәвамында озата йөрсә, дөньяви мәдәният шул үрнәкләр турында тукып торса...

pixabay.com

Үрнәкләр юкмы, әллә?..

Үсмер чорда, яшьлектә «дөрес буласы» килмәү модасы көчле инде ул. Ике кыз үстерүче журналист Раилә Хәялиева да шундый фикердә.

– Олы кызыбызга 8 яшь. Быел көз чәченә ак бант кушып үргәндә, ул үзен «подросток» дип игълан итте. Аларның чәче дә, киемнәре, хәтта сөйләшүләре дә башка төрле була икән. «ТикТок» караган бу. Башка «подросток»лар белән. Бу сүз белән өйгә Моргенштерн да кайтты. Тыныч кына табак-савыт юганда кызым минем аның кем икәнен беләмме-юкмы икәнлегемне тикшереп карады. Аннан җырлары, акчасы, кызык-мызыклары хакында сөйләде. Аңа чаклы җәйге каникул чорында яңа герой – Влад Бумага белән танышкан иде. Телефон карауны өйдә 10 минуттан арттырмасак та, бала бит җәмгыятьтә яши. Мин генә чикләр куеп бетерә алмыйм. Кызыксынуларын аның күз алдында себереп түгәргә ярамый. Мин дә кызыксынам, сораулар бирәм, кызым белән бер дулкында булырга тырышам. Нәкъ шул чорда бала күңелендә чагыштырып карау өчен башка төрле геройлар да – уңайлары да булырга тиешлеген аңладым мин. Дөнья ул күргән Влад, Моргенштерн... гына түгел икәнен күрсәтергә, – ди ул. – Чынлап әйткәндә, уңай каһарманнар белән хәлләр авыррак шул. Суда батучы, янгыннан коткаручылар хакында да артыгын сөйләргә ярамый балага. Алар бит максималист, уйламый эш йөртүләре, батырлык хакына махсус нидер эшләп куюлары бар. Бүлмәсендә тыныч кына йоклап китәргә курыкса да, яшьләрне куркыныч әйберләр, «ялган герой»лар үзенә тарта. Әни буларак, мондый пропаганда мине куркыта. Бик куркыта! Шуңа күрә бала белән күбрәк аралашырга, ул кызыксынган әйберләрдән көлмәскә, кимсетмәскә, ә күбрәк дөньяның яктылыгын, тырышлык аша үскән уңыш тарихларын, гади тормыш ямен, ялган тарихларның тиз уалуын күрсәтергә кирәк дигән фикердә мин.

Сан

Соңгы биш елда илдә наркотик кулланучылар саны кимегән. Россия Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматларына караганда, тыелган матдәләр куллану проблемасы белән ил халкының **1** процентган азрагы очрашкан. Бу – якынча **2** млн кеше дигән сүз.

Әлегә. Чөнки «подростогым» үсә генә башлады...

Бер тапкырдан берни булмас

Соңгы арада мактауга лаек булмаган, асылда бик зыянлы һәм куркыныч күренешләрне күккә чөю, аларның табигый булуын исбатларга тырышу, бер сүз белән әйткәндә, романтикага төреп бирү, кызганыч, гадәти хәл санала. Аеруча яшь буын арасында. «Макталуга» психик авырулар, наркотик һәм психотроп матдәләр, алкоголь куллану, селфхарм (үзеңә зыян салу. – **Ред.**), тәртипсез җенси мөнәсәбәтләр лаек икән.

Уйлап карасаң, поп-мәдәният әлеге күренешләрнең уңай образын тудыруда үзе үк гаепле. Яшь буын караган, укыган, тыңлаган, җан аткан күренешләрнең күпчелегендә шушылар алга сөрелә бит. Турыдан-туры түгел, билгеле. Әмма җитлекмәгән аңга азы да бата.

Яшь буынның үрнәге кем? Төгәлрәк әйткәндә, күпчелек идеал итеп күргән зат, аның портреты нинди? Ирекле, җәмгыять калыпларына каршы чыккан, кагыйдәләрне санга сукмаган, гамәлләре белән үзенә җәлеп итеп торган шәхес ул. Әлбәттә, аның да гүзәл сыйфатлары бардыр. Әмма яшь аң аның тискәреләрен генә кабул итә. Ул табынган герой тәмәке тарта, моның өчен җәзасыз кала икән, нишләп әле миңа да шулай эшләп карамаска, ди ул. Болай эшләсә, аның башка иптәшләре арасында абруе да, кәттәлеге дә арта.

Тәмәкедән дә куркынычрак гамәлләр бар әле. Әйтик, шушы көннәрдә яшьләрнең күңелен яулап алган бер сериалның яңа сезоны чыкты. Сюжет үзәгендә – үсмер кызның рөхсәт ителмәгән нәрсәләргә бай тормышы. Наркотиксыз тормышны күз алдына да китерә алмый ул. Аның һәм яшьтәшләре өчен болар барысы да – табигый һәм күңел ачу чарасы гына. Сериалны шашып караучы аудитория – үсмерләр һәм яшьләр.

Узган атнада Американың «D.A.R.E» оешмасы (наркотиклар куллануны, үсмерләрне бандаларга җәлеп итү һәм балигъ булмаганнар арасында агрессив тотышны булдырмау максатыннан эшлиләр. – **Ред.**) активистлары бу сериалны гаепләп тә чыкты. «Һәр ата-ананың балаларын наркотиклардан явызларча файдалану һәм башка куркыныч күренешләрдән саклап калуны кисәтүгә теләктәшлек күрсәтер урынга, сериал хәзерге дөньяда киң таралган деструктив тәртипнең башка төрләрен ялгыш рәвештә таныта», – диелә аларның мөрәҗәгатендә.

БЕЛГЕЧ СҮЗЕ

Мәгълүмати ташкында барысын да күз уңында тотып та булмый, билгеле. Практик психолог **Зөһрә Кәримова** да шундый фикердә. Нәрсәнедер тыеп кына уңай нәтиҗәгә ирешеп булмаячак. Бәлки әле кире нәтиҗә дә булмагае.

– Бәйлелек турында күп сөйлиләр, күп бәхәсләшәләр. Минемчә, мондый төр контентны – фильм, китап, җыр һәм башкасын – кулланырга ярый, әмма чама хисен югалтмаска кирәк. Бу ешлыкка да кагыла. Карыйсың, тыңлыйсың, укыйсың икән, һичшиксез, бу хакта бала белән сөйләшү, фикер алышу мөһим! – ди ул.

Яшүсмернең начар үрнәкләргә вакыты азрак калсын өчен шөгыле булырга тиеш. Бәйлелек корбаны булмауның төп чарасы менә шул, ди психолог.

– Яңа хисләр, яңа тойгылар бүләк итә торган чаралар бихисап. Төрле иҗади түгәрәкләр бар. Балаларны шунда бирергә кирәк. Әйткәнемчә, сөйләшү, фикерләшеп тору мөһим. Баланың нәрсә турында уйлавы белән кызыксынып торырга кирәк. Гомумән, яшь аң гел нәрсә беләндер мәшгуль булса яхшы, – дип искәртә белгеч.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

75 ЯШЬЛЕК МӨХӘРӘМ МӨХӘММӘТҖАНОВ:

«КЕШЕЛӘРГӘ ФАЙДА КИТЕРЕРГӘ ТЕЛИМ»

Агроном, икътисад фәннәре докторы, Буа районының легендар шәхесе Мөхәрәм Мөхәммәтҗановны республикада да, читтә дә беләләр. Бөтен гомерен җиргә, туган ягына хезмәт итүгә багышлаган Мөхәрәм абый бүген дә гел хәрәкәттә. «Блогер.Татар» республикакүләм бәйгесе җиңүчесе белән авыл, тормыш, блогерлык эше турында сөйләштек.

Буада 28 йортлык «Мөхәрәм урамы» бар. Аның тырышлыгы белән барлыкка килгәнгә шул исемне йөртә ул. Һөнәре буенча – агроном. Озак еллар үзе булдырган «Зөя» ярма заводында ниләр генә җитештермәгән?! Карабодай, борчак, солы кебек культуралар – берсе дә калмаган.

1979 елда Мөхәрәм абый, партия кушуы буенча, ул чактагы «Искра» хуҗалыгы белән җитәкчелек итә башлый, Татарстанның колхозлар Советы рәисе итеп сайлана. 1989 елда Мәскәүгә китә, СССРның Югары Советында эшли башлый. Союздаш һәм автоном республикаларның социаль-икътисади үсеше мәсьәләләре буенча комиссияне җитәкли. Күпьеллык намуслы хезмәте, ирешкән уңышлары өчен «Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек була. Әле тагын күпсанлы мактаулы исемнәр, бүләкләр иясе ул.

Күптән түгел генә дә Мөхәрәм абый өченче «Блогер.Татар» республика бәйгесендә җиңү яулады. «Инстаграм»дагы аккаунтын бик кызыклы итеп алып бара. Аның сүзләренчә, кешеләргә яхшылык эшләү, ярдәм итү аңа яшәү дәрте, җан тынычлыгы бирә.

– «Инстаграм»да аккаунтым бар, ләкин анда сирәк керә идем. Бер танышым үземнең тарихны китапка язып калдырырга тәкъдим итте. Ләкин миңа укучыларым белән турыдан-туры аралашу кирәк. Китапны аны минем язмаларга нигезләнеп балаларым, оныкларым да чыгара ала. Шулай итеп бу эшчәнлекне «Инстаграм»да башлап җибәрдем. Мине кешеләрнең психологиясе, аларның тормышка карашы кызыксындыра. Блог белән акча эшләргә җыенмыйм. Белгән әйберне башкалар белән дә уртаклашырга кирәк. Иң мөһиме – кешеләргә хәзерге вакытта булган авырлыкларны бераз гына булса да җиңеләйтү. Безгә бит хәзер аралашу җитми, минем

яшьтәгеләргә аеруча. Бу авыру безне капка артына бикләде, – ди ул.

Бүген аның «Инстаграм» битендә 1407 язылучысы бар. Мөхәрәм абый әйтүенчә, сайлап алынганнар гына җыелган анда.

– Һәрберсе – үзе сайлап кына, озак күзәтеп барганнан соң гына кергән кешеләр. Үземне блогер итеп танытасым килми. Алар мине карыйлар, яраталар, язалар икән – шул җитә. Мине кирәкле дип тапканнары өчен рәхмәт аларга, – дип сөйли Мөхәрәм абый. – Оныкларым да: «Әйдә, бабай, аккаунтыңны үстерик, 5000, 10000 язылучың булыр», – дип әйтәләр. Аралашыр өчен кердем, реклама бирергә җыенмыйм, дип җавап бирәм. Миңа язылучыларның сорау бирүләре, аңламаган әйберләрне аларга аңлатып бирү, аларның тормышларын белеп тору кирәк.

Мөхәрәм абыйның аккаунтындагы постларны еш кына зур пабликлар үзләренә алып куя.

– Боларның берсе дә реклама ясау максатыннан түгел, ә кешеләр белән кичерешләрне бүлешеп, тормышны җиңеләйтү, нинди дә булса өлеш кертү өчен. «Блогер» исеме мине кызыксындырмый. Мәсәлән, бер тимерне тимер икәнен генә язасың икән – син блогер дип саналасың ди, ә менә аның эченә кереп, тимернең кемгә, ничек һәм ни өчен хезмәт итә ала икәнен күрсәтерлек дәрәҗәгә ирешү – монысы икенче нәрсә, – ди ул.

Алга таба планнары да зурдан аның:

– Язылучыларым белән сөйләшәсе, язасы әйберләрем күп әле. Үзем өчен якын булган ике авыл тарихына күбрәк тукталасым килә. Берсе – туган авылым Күл Черкене, икенчесе, иң күп хезмәт куйганы – Яңа Тинчәле авылы. Күл Черкене – районның иң атаклы авылларының берсе. Зөя елгасы буенда урнашкан ул. Халкы бик тырыш, бүген анда яшәр өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар. Яңа Тинчәле 3000гә якын кешеле 2 авылдан торган колхоз иде. Авыл яшәеше, күтәрелеше, халкының тормышка бирелгәнлеге, ул як мишәрләренең үзләренә генә хас аерым яклары бар, шулар турында истәлек язып калдырасым килә, – ди ул.

Мөхәрәм абый 1991 елдан бирле Буада яши. «Авылда яшәү рәхәтме, шәһәрдәме?» – дип сорыйм үзеннән. «Минем өчен бернинди дә аерма юк. Яшәү шартлары икесендә дә әйбәт. Үзебезнең урамга үзем асфальт керттем, авылның бүген теләсә нинди урамына барып керсәң – таш җәелгән, юл бар. Шәһәрдә дә, авылда да газ, су кертелгән», – дип җавап бирде.

Хатыны Гөлфия апа белән икәү гомер кичерәләр, балалары читтә яши.

– Без бер тик тора белмибез. Икебез дә иртән чыгып китәбез дә эшләп йөрибез. Кайвакытта икебезнең кулда – ике телефон, бакчаның бер башыннан икенче башына телефон аша аралашабыз. Беребез өйдә, беребез бакчада эшләгәндә, 1–2 сәгать югалышып торсак, телефоннан табышабыз, – ди Мөхәрәм абый.

Бакча эшләрен бик яратып башкара ул. Табигатькә бирелеп, аның белән бергә яшәргә, яратырга кирәк. Ул, үсемлекләр янында чын-чынлап ял итәм, көч алам, ди.

Менә шулай күңел кушуы буенча, тормыштан ямь, хезмәттән тәм табып яши Мөхәрәм Мөхәммәтҗанов. Моның сере дә гади: «Әгәр кеше тынгысыз, эзләнә икән, барыбер үзенә кирәклесен таба», – ди ул.

Ләйсән САФИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7080 данә
Гомуми тираж – 17126 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 219

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+